Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы
КАРАРЫ

«11» март 2025 ел. № 119

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советына депутатлар сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын раслау турында**

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль законның 18 статьясы, Татарстан Республикасы Сайлау кодексының 2007 елның 07 маендагы 21-ТРЗ номерлы 25, 26 статьялары, «Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 38 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Иске Казиле авыл җирлеге Советы

**Карары:**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Иске Казиле авыл җирлеге Советы депутатларын сайлауларны уздыру өчен бермандатлы сайлау округлары схемасын ун елга расларга (кушымта итеп бирелә).

2. Әлеге карарны, бермандатлы сайлау округлары схемасын да кертеп, график сурәте белән бергә, 2025 елнын 16 мартыннан да соңрак булмаган вакытта Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматын рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru), шулай ук Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге рәсми сайтында (kamskoye-ustye.tatarstan.ru) бастырып чыгару юлы белән хэм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында халыкка игълан итәргә:

1) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Иске Казиле авылы, Һади Такташ ур., 4;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Каратал авылы, Күпер урамы, 5;

2) Татарстан Республикасы, Кама Тамагы муниципаль районы, Атабай авылы, Үзәк урам, 14.

3. Карар ул басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге башлыгы,
Кама Тамагы муниципаль районы
Иске Казиле авыл җирлеге Советы рәисе И.Х.Сагьдиев